РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» мая 2025 ел г. Альметьевск №1139

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 29 маендагы 1050 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 3 апрелендәге 03-12/2212 номерлы хаты нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 29 маендагы 1050 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 июнендәге 1182 номерлы, 2020 елның 16 июлендәге 959 номерлы, 2020 елның 9 декабренге 1805 номерлы, 2022 елның 25 октябрендәге 2448 номерлы, 2023 елның 27 июнендәге 1974 номерлы, 2024 елның 21 маендагы 1847 номерлы,2024 елның 19 ноябрендәге 3685 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 һәм 3 пунктларында «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе үзәкләштерелгән бухгалтериясе " сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура һәм спорт идарәсе үзәкләштерелгән бухгалтериясе»сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Карарның 4 пунктында «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» һәм «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура һәм спорт идарәсе» һәм «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура һәм спорт идарәсенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» сүзләренә алмаштырырга;

заказ № 1-851

1.3. Карарның 1 нче кушымтасында:

а) нигезләмә исемендә «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе үзәкләштерелгән бухгалтериясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура һәм спорт идарәсе үзәкләштерелгән бухгалтериясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1-5 пунктларда «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе үзәкләштерелгән бухгалтериясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының физик культура һәм спорт идарәсе үзәкләштерелгән бухгалтериясе» сүзләренә алмаштырырга.;

в) 3 пункт таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфасы | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе (бүлеге) булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 41 500 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 39 800 | |
| Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 39 800 |
| Бүлек җитәкчесе | 33 500 | 33 500 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 29 500 | 29 500 |
| Әйдәп баручы белгеч (эшчәнлек юнәлеше) | 29 500 | 29 500 |
| Бухгалтер | 27 800 | 27 800 |
| Белгеч (эшчәнлек юнәлеше) | 27 800 | 27 800 |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Ә. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова